ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 20 - 19.01.2021

**"Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә" үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 276 номерлы «мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» гы карары белән расланган компенсация түләүләрен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 2.1.1 пунктын өстәргә:

«2.1.1.Әлеге тәртип буенча социаль ярдәм чараларын алу шарты булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү тора.».

2.Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга .pravo.tatarstan.ru) Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту мәгариф бүлеге начальнигы Г. Б. Галләмеевага йөкләнде.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**